**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР | ПОСТАНОВЛЕНИЕ

от ______________ ПГ-43 26.11.2024 № ____________

Актаныш муниципаль районы Башлыгының "Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең класс чиннары турында" 01.10.2015 ел, ПГ-33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 02.11.2023 ел № 99-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп,

карар бирәм:

1. Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 17 пунктына үзгәреш кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«17. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 20 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чины бирү хакында тәкъдим барлык кирәкле документлар белән бергә җирле үзидарәнең класс чиннары бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына кергән көннән алып бер айгадан да соңрак булмаган срокта кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы Л. Р. Зарипов